ФӘНИЛ МАНСУРОВ

# ЮЛ ЧАТЫНДА КӨМЕШ ӘРЕМ





ФӘНИЛ МАНСУРОВ

# ЮЛ ЧАТЫНДА КӨМЕШ ӘРЕМ



ПОВЕСТЬЛАР

КАЗАН · ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ · 1978

С(Тат)2
М23

Художнигы С. ҚУЛЬБАҚА

Бу китапта язучының «Юл чатында көмеш әрем» һәм «Яктытауда бүз тургайлар» исемле ике повесте урнаштырыла. Яшүсмерләргә багышланган бу әсәрләрдә аларның тормышта беренче адымнары, беренче мәхәббәтләре һәм беренче тирән кичерешләре сурәтләнә.

УРТА ЯШЬТӘГЕ МӘКТӘП БАЛАЛАРЫНА

М 70803—061 / М132(03)—78 130—78

© Татарстан китап нәшрияты, 1978.

# ЮЛ ЧАТЫНДА КӨМЕШ ӘРЕМ

## I

Өч юл чаты...

Бер кулым белән иңбашымдагы сумка бавын тотып, икенчесе белән күзләремне кояштан ышыклап, бәхет кошын эзләүче Алпамша шикелле, өч юл чатында туктап калдым.

Әйе, өч юл... Аларның көньякка юнәлгәне Өфегә бара, төньякка киткәне Дүртөйлегә, турыга — көнчыгышка сузылганы биредән чакрым ярымдагы Кушнаринга керә. Тик аларның кайсыннан миңа юл алырга? Чыннан да, әкияттәге Алпамша хәлендә калдым: уңга китсәң — атың үлә, сулга китсәң — үзең, ә турыга... Дөрес, Кушнаринда да пристань бар, пароходның теләсә кайсына утыр да Агыйделдән әйдә түбәнгә, аннары... аннары... Иделдән Казан каласына. Башкача уйлыйсы да юк. Әмма анда, пристаньга якын гына култыкта, безнең колхозныкылар сал чыгара. Әгәр аларның берәрсе күрә калса — харап, минем кая киткәнне белеп, әтигә хәбәр итә дә итә... Өфе автобусыннан төшеп калгач, менә шулай аптырауга калдым. Алдымда өч юл, югыйсә...

Кечкенә башымны авылдагы хәсрәт-уй болай да катырган иде.

Шунда борыныма әче ис бәрелде. Башымны иеп түбән карасам — аяк астында җәелеп үскән әрем. Үзе ваквак яфракларының һәр бөртегенә кадәр тузанга баткан. Шулай да ул бетәшкән түгел, җилдә хәйран җилфердәп утыра... Уйласаң гаҗәп: бу үсемлекне таптап та үтәләр, сындыралар, йолкалар да. Барыбер аның өчен гомернең ахыры юк сыман. Ул ашсыз җирдә дә, каты җирдә дә, хәтта ташта да үсә бирә... Борын заманда, имеш, бер чәчән, тугры-хак сүз өчен гомерлеккә читкә сөрелеп, бик күп еллар еракта, Кафтау артында яшәргә мәҗбүр булган. Сакал-мыеклары тәмам агарып, күзләренең кәре[1]

[1] Куәте, көче.

— Кая чабасың, аш өлгерде?!— дип кычкырды.

Туктамадым, өй артындагы бакчадан койма аша сикердем дә тыкрыктан урамга йөгереп чыктым.

Яктытау мине — тишек борынлы кечкенә тимерчене — гадәттәгечә колачын җәеп каршы алды. Минем бөтен төшем — якты дөньяга сокланып туймаган яшькелт күзләрем, ике якка тырпаеп баскан колакларым, хәтта тез башлары ямаулы зур чалбарым белән аягымдагы «чачаклы» иске чабатам да Яктытауга бик тә таныш иде. Үз чиратында Яктытау — сөзәк кенә югары күтәрелгән сихри итәге, җиргә ятып уйнаган көчле җиле, зәңгәрсу күкне иңрәтеп сайраган бүз тургайлары — һәммәсе, һәммәсе белән бергә мине дә үзенә тәмам гашыйк иткән иде. Яктытау итәгендә бер мизгелгә тукталып, тирә-ягыма әйләнеп карадым. Әнә мине Мүкләк сөзеп ыргыткан урын... Менә Миша дәдәй сыердан аралаган төш... И-их, шул сөзгәк әле дә исән булса иде, мине өч-дүрт метрга ыргытып, Миша дәдәйнең көчле кулларына барып төшәсе иде... Әнә ул киткән юл, ирләр кулындагы кан тамыры төсле, боргалана-боргалана еракка сузылган... Кинәт кенә сулышымны тыеп, башымны артка ташлап, зәңгәрсу күккә карадым. Ә анда Тәзкирәнең йон тубына охшаш бүз тургайлар бар тирәне иңрәтеп сайрыйлар иде. Карале, карале, хас та Мүкләк муенындагы кыңгырау. Челдерр... челдеррр!.. Әллә алар да Мүкләкне һаман юксыналармы?.. Әлеге мине — тишек борынлы кечкенә тимерчене — җиргә ятып уйнаган көчле җил бөтереп алды да Яктытауның сихри итәгеннән күпереп яткан җылы сулышлы кин күкрәгенә очыртып мендерде.

Ә биредә шундый биеклек, бөтен тирә-як уч төбендәге шикелле күренә: аста, Яктытаудан читтәрәк йөзенә зәңгәр эңгер бөркәнгән тып-тын авыл, яңа сөрелгән кап-кара басу башында — алсу офыклар...

Бу күренеш күптән таныш булса да, бүген, беренче мәртәбә күргәндәй, бер авылга, бер ерактагы офыкларга карап, тиле кеше төсле, үз-үземә сөйләндем:

— Ник син болай моңсу, авылым? Кичке эңгер үтәр дә китәр. Төн артыннан кыелып таң атар. Менә күрерсең, иртәгә дә көн аяз булачак. Әйткән иде диярсең. Әнә күрәсеңме, офыклар нинди алсу...

ЭЧТӘЛЕК


Юл чатында көмеш әрем . . . . . . . . . . . . . . 5

Яктытауда бүз тургайлар . . . . . . . . . . . . . . 48



*Мансуров Фаниль Хабибуллович*

СЕРЕБРИСТАЯ ПОЛЫНЬ

Повесть

(на татарском языке)

Рецензенты *Флорид Әгъзамов*

Редакторы *Резеда Вәлиева*

Художество редакторы *Г. Е. Трифонов*

Техник редакторы *С. Г. Әхмәтҗанова*

Корректорлары *З. К. Бикмөхәммәтова, З. М. Миңнуллина*

ИБ № 1142

Наборга бирелде 24/VIII-1977 ел. Басарга кул куелды 2/II-1978 ел. Типография кәгазе № 1, 84×108 1/32. Учетн.-изд. табагы 5,92. Якынча басма табагы 5,88. ПФ 04012. Заказ В-714. Тираж 11000. Бәясе 20 тиен.

Татарстан китап нәшрияты. Казан, Бауман ур., 19.

Татарское книжное издательство. Казань, ул. Баумана, 19.

ТАССР Министрлар Советының Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре идарәсенең Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. Казан, Бауман ур., 19.